МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

25.08.2023 Казан шәһәре №180

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә раслау хакында» 2018 елның 22 маендагы 232 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә раслау хакында» 2018 елның 22 маендагы 232 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2022 елның 7 октябрендәге 359 номерлы, 2023 елның 9 мартындагы 57 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

боерыкның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Кушымталарда бирелгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә;

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе составын.»;

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәнең 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министр Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет, Министрлыкта билгеләнгән тәртиптә эшләүче беренчел профсоюз оешмасы һәм Министрлыкта

булдырылырга мөмкин булган ветераннарның иҗтимагый оешмасы вәкилләрен Комиссия составына кертү турында карар кабул итә ала.»;

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе составын өстәргә (кушымтада бирелә).

**Татарстан Республикасы**
**Премьер-министры урынбасары –**
**министр** **М.Р.Шаһиәхмәтов**

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2018 елның 22 маендагы 232 номерлы боерыгы белән расланды
(Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2023 елның 25 августындагы 180 номерлы боерыгы редакциясендә)

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Әмирханов Роман Дамир улы | Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары – Социаль-икътисадый мониторинг департаменты җитәкчесе |
| Садыйкова Венера Рузвельт кызы | дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге җитәкчесе, комиссия рәисе урынбасары |
| Вафина Зөлфия Әнвәр кызы | дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенең әйдәп баручы белгече, комиссия секретаре |

**Комиссия әгъзалары:**

| | |
|---|---|
| Шәрәфетдинов Рәис Мифтах улы | эшләр идарәчесе |
| Баһаветдинова Диләрә Минимулла кызы | юридик бүлек башлыгы |
| Панкратов Алексей Юрьевич | Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенең оештыру бүлеге мөдире |
| Юрьева Оксана Владимировна | социология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университетының Идарә, икътисад һәм финанслар институтының кеше ресурслары белән идарә итү кафедрасы доценты (килешү буенча) |
| Шаһиева Рауза Абдрахман кызы | «Татарстан Республикасы икътисадый җәмгыяте» иҗтимагый оешмасы вице-президенты, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет әгъзасы (килешү буенча) |